РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

28 март 2024 ел №236

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 63 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроле турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Чирмешән районы прокуратурасының 2024 елның 16 февралендәге №02-08-01/89-р «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә» протестын карап чыгып Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 63 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 215 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 63 номерлы карары белән расланган «Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контроль чараларын үткәрү өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары» 2 нче кушымтасын (район Советының 2022 елның 27 гыйнварындагы 90 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча карарларны үз эченә алган муниципаль торак фондының торак биналары булган күпфатирлы йортта милекчеләрнең гомуми җыелышының ике һәм аннан да күбрәк беркетмәсен өч ай рәттән муниципаль торак контроле органына кертү.

2. Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматларына караганда, контрольдә тотылган зат идарәсендәге күп фатирлы йортта гомуми милектәге җитешсезлекләрне бетерү буенча эшләр башкару өчен атнага биштән артык ремонт бригадасы чакыру очраклары.

3. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларында күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда 50% тан артык арттыру турында белешмәләрне ачыклау.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов